РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17 июля 2019г. №_261

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 нче елның 31 нче августындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 337 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 14 нче августындагы “Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 665 номерлы карарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 нчы елның 21 нче июнендәге Дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм аерым типка карамаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 505 номерлы карарына нигезләнеп, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм аерым типка карамаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августындагы 337 номерлы нигезләмәсенә, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1. Әлки муниципаль районының яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм аерым типка карамаган оешмалары хезмәткәрләренең 2018 елның 31 августындагы 337 номерлы хезмәт хакы шартлары турындагы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V бүлегендә:

2.4 пунктының алтынчы абзацында “26,5"санын "41,0" санына алмаштырырга;

6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6 нчы таблица”

**Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процентта |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | Беренче - дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0 |

4.4 пунктының алтынчы абзацында “26,5"санын "41,0" санына алмаштырырга;

11 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11 нче таблица”

**Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Вазыйфа атамасы | Өстәмә түләү күләме, процентта |
|---|---|---|
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 41,0 |
| “Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | аккомпанатор, костюмер мөдире | 49,0 |
| | түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, мәнфәгатьләр клубы җитәкчесе, культорганизатор | 61,0 |
| "Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | 49,0 |

| | | |
|---|---|---|
| "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |

VIII бүлегендәге 8 пунктның бишенче абзацында «10» санын «20 " санына алмаштырырга.

2.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3.Әлки муниципаль районының рәсми порталының интернет челтәрендә бастырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.